**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Тюгеевского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлегенең**
**башкарма комитеты**

ул. Центральная, д. 8, с. Тюгеевка,
Заинский район, 423507

Үзәк урамы, 8 нче йорт, Төги
авылы, Зәй районы, 423507

Телефон, факс 60-5-02. Электронный адрес: Turg.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**02.02.2026 г.** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ Федераль законына, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында 23.01.2026 № 30 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары беләнЗәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Уставына таянып

**карар бирәм:**

1. 2026 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9678,63 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2025 елның 31 гыйнварындагы 89 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4.Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй

муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Т.В. Попова**

Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлеге
башкарма комитетының
02.02.2026 ел
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән
Төги авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3681,26 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1573,45 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4423,92 |
| Барысы | 9678,63 |

Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлеге
башкарма комитетының
02.02.2026 ел
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән
Төги авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
| --- | --- |
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 1009,41 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2747,27 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1535,83 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4386,12 |
| Барысы | 9678,63 |